**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об отдельных вопросах организации регулярных перевозок пассажиров и багажа автомобильным транспортом и городским наземным электрическим транспортом в Республике Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
19 февраля 2026 года

## Статья 1

Внести в Закон Республики Татарстан от 26 декабря 2015 года № 107-ЗРТ «Об отдельных вопросах организации регулярных перевозок пассажиров и багажа автомобильным транспортом и городским наземным электрическим транспортом в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2015, № 12 (I часть); 2016, № 7 – 8; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 55 (часть I); 2018, № 29 (часть I); 2022, № 57 (часть I); 2023, № 35 (часть I), № 95 (часть I) следующие изменения:

1) в части 2 статьи 3:
а) в пункте 4 слова «выдает свидетельство об осуществлении перевозок по межмуниципальному маршруту регулярных перевозок и карты маршрута регулярных перевозок» заменить словами «предоставляет право осуществления перевозок по межмуниципальному маршруту регулярных перевозок»;
б) пункт $4^1$ признать утратившим силу;

2) в статье 4:
а) в пункте 4 слова «выдают свидетельство об осуществлении перевозок по муниципальному маршруту регулярных перевозок и карты маршрута регулярных перевозок» заменить словами «предоставляют право осуществления перевозок по муниципальному маршруту регулярных перевозок»;
б) пункт $4^1$ признать утратившим силу;

3) в статье 5:

а) в части 6 слова «выдано свидетельство об осуществлении» заменить словами «предоставлено право осуществления», слова «такого свидетельства» заменить словами «такого права»;

б) в части $6^1$ слова «выданы свидетельства об осуществлении» заменить словами «предоставлено право осуществления», слова «таких свидетельств и карт данных маршрутов» заменить словами «такого права»;

в) часть 7 дополнить предложением следующего содержания: «Право осуществления регулярных перевозок по муниципальному и межмуниципальному маршрутам регулярных перевозок подтверждается записью в реестре муниципальных и межмуниципальных маршрутов регулярных перевозок.»;

4) в статье $5^1$:

а) дополнить частью $2^1$ следующего содержания:

«$2^1$. Реестры маршрутов регулярных перевозок ведутся на электронных носителях.»;

б) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. В реестры маршрутов регулярных перевозок должны быть включены сведения, предусмотренные частью 1 статьи 26 Федерального закона. Сведения, содержащиеся в реестрах маршрутов регулярных перевозок (за исключением сведений о месте жительства индивидуального предпринимателя), подлежат размещению на официальном сайте уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан или уполномоченного органа местного самоуправления в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет», к полномочиям которого относится ведение данных реестров, по форме, установленной федеральным органом исполнительной власти, осуществляющим функции по выработке государственной политики и нормативно-правовому регулированию в сфере транспорта.»;

5) в части 4 статьи 6 слова «свидетельством об осуществлении перевозок по соответствующему маршруту регулярных перевозок» заменить словами «записью в реестре соответствующего вида маршрута»;

6) в статье 7:

а) наименование изложить в следующей редакции:

«Статья 7. **Предоставление права осуществления перевозок по маршруту регулярных перевозок и выдача карт соответствующего маршрута, прекращение действия предоставленного права**»;

б) в части 1 слова «Свидетельство об осуществлении» заменить словами «Право осуществления», слова «и карты соответствующего маршрута выдаются» заменить словом «предоставляется»;

в) в части 2 слова «Свидетельство об осуществлении» заменить словами «Право осуществления», слова «и карты соответствующего маршрута выдаются» заменить словом «предоставляется»;

г) в части 3:

в абзаце первом слова «свидетельство об осуществлении» заменить словами «право осуществления», слова «и карты» заменить словами «предоставляется и карты»;

пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1) после наступления обстоятельств, предусмотренных пунктами 1, 2, 7, 9 и 11 части 1 статьи 29 Федерального закона, и до начала осуществления регулярных перевозок в соответствии с новым правом осуществления перевозок по маршруту регулярных перевозок, предоставленным по результатам проведения открытого конкурса. По обстоятельствам, предусмотренным частью 10 статьи 24 Федерального закона, предоставление права осуществления перевозок по маршруту регулярных перевозок победителю открытого конкурса, признанного несостоявшимся, не допускается;»;

в пункте 3 слова «свидетельством об осуществлении» заменить словами «правом осуществления», слово «выданным» заменить словом «предоставленным»;

д) в части $3^1$ слова «свидетельства об осуществлении» заменить словами «право осуществления», слова «и карты соответствующих маршрутов выдаются» заменить словом «предоставляется»;

е) в части 4 слова «свидетельство об осуществлении» заменить словами «право осуществления», слова «и карты маршрута регулярных перевозок выдаются» заменить словом «предоставляется», слова «их выдачи» заменить словами «его предоставления», слова «выданного свидетельства об осуществлении» заменить словами «предоставленного права осуществления», слова «указанного свидетельства» заменить словами «указанного права»;

ж) дополнить частью $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$. Карты маршрута регулярных перевозок по муниципальному маршруту регулярных перевозок, межмуниципальному маршруту регулярных перевозок выдаются юридическим лицам, индивидуальным предпринимателям, участникам договора простого товарищества, которым предоставлено право осуществления перевозок по соответствующему маршруту, уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан или уполномоченными органами местного самоуправления, установившими данные маршруты. Указанные карты маршрута регулярных перевозок выдаются на срок, на который юридическому лицу, индивидуальному предпринимателю, участнику договора простого товарищества предоставлено право осуществления перевозок по соответствующему маршруту регулярных перевозок.»;

з) в части 5 слова «свидетельства об осуществлении» заменить словами «предоставленного права осуществления»;

и) в части 6 слова «выдавшие свидетельство об осуществлении» заменить словами «предоставившие право осуществления», слово «свидетельства» заменить словом «права».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу с 1 марта 2026 года, за исключением пунктов 1, 2, 4 и 6 статьи 1 настоящего Закона.

2. Пункты 1, 2, 4 и 6 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 сентября 2026 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
21 февраля 2026 года
№ 12-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 19 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 35 (I өлеш), № 95 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә:
а) 4 пунктта «даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирә» сүзләрен «даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукын бирә» сүзләренә алмаштырырга;
б) $4^1$ пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 4 статьяда:
а) 4 пунктта «даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталарын бирәләр» сүзләрен «даими рәвештә пассажирлар

йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукын бирәләр» сүзләренә алмаштырырга;

б) $4^1$ пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 5 статьяда:

а) 6 өлештә «гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы бирелгән» сүзләренә алмаштырырга, «мондый таныклык» сүзләрен «мондый хокук» сүзләренә алмаштырырга, «мондый таныклыкның» сүзләрен «мондый хокукның» сүзләренә алмаштырырга, «әлеге таныклыкның» сүзләрен «әлеге хокукның» сүзләренә алмаштырырга;

б) $6^1$ өлештә «гамәлгә ашыру хакында таныклыклар бирелгән» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы бирелгән» сүзләренә алмаштырырга, «мондый таныклыкларның һәм шушы маршрутлар карталарының» сүзләрен «мондый хокукның» сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль һәм муниципальара маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукы даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль һәм муниципальара маршрутлары реестрында язма белән раслана.»;

4) $5^1$ статьяда

а) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрлары электрон саклагычларда алып барыла.»;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрларына Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлешендә каралган белешмәләр кертелергә тиеш. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрларында булган белешмәләр (индивидуаль эшкуарның яшәү урыны турындагы белешмәләрдән тыш) транспорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы билгеләгән рәвештә үз вәкаләтләренә шушы реестрларны алып бару кертелгән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының яисә вәкаләтле җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.»;

5) 6 статьяның 4 өлешендә «даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «тиешле тәрдәге маршрут реестрында язма» сүзләренә алмаштырырга;

6) 7 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. **Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукын һәм тиешле маршрут карталарын бирү, бирелгән хокукның гамәлдә булуын туктату**»;

б) 1 өлештә «гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы» сүзләренә алмаштырырга, «һәм тиешле маршрут карталары» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 2 өлештә «гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы» сүзләренә алмаштырырга, «һәм тиешле маршрут карталары» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 3 өлештә:

беренче абзацта «гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Федераль законның 29 статьясындагы 1 өлешенең 1, 2, 7, 9 һәм 11 пунктларында каралган шартлар барлыкка килгәннән алып ачык конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча бирелгән даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруның яңа хокукы нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра башлаганчы. Үткәрелмәгән дип танылган ачык конкурста җиңүчегә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукын бирү Федераль законның 24 статьясындагы 10 өлешендә каралган шартлар буенча рөхсәт ителми;»;

3 пунктта «гамәлгә ашыру турында яңа таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашыруның яңа хокукы» сүзләренә алмаштырырга;

д) $3^1$ өлештә «гамәлгә ашыру турында таныклыклар» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы» сүзләренә алмаштырырга, «һәм тиешле маршрутлар карталары» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 4 өлештә «гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукы» сүзләренә алмаштырырга, «һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталары аларны» сүзләрен «аны» сүзенә алмаштырырга, «гамәлгә ашыру турында элек бирелгән таныклыкның» сүзләрен «гамәлгә ашыруның элек бирелгән хокукының» сүзләренә алмаштырырга, «күрсәтелгән таныклыкның» сүзләрен «күрсәтелгән хокукның» сүзләренә алмаштырырга;

ж) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

«$4^1$. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут карталары тиешле маршрут буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукы бирелгән юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларга бу маршрутларны билгеләгән вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан бирелә. Даими рәвештә пассажирлар

йөртү һәм багаж ташу маршрутының күрсәтелгән карталары юридик затка, индивидуаль эшкуарга, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыга даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукы бирелгән срокка бирелә.»;

з) 5 өлештә «гамәлгә ашыру турында таныклыкның» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукының» сүзләренә алмаштырырга;

и) 6 өлештә «гамәлгә ашыру турындагы таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашыру хокукын» сүзләренә алмаштырырга, «таныклыкның» сүзен «хокукның» сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1, 2, 4 һәм 6 пунктларыннан тыш, 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1, 2, 4 һәм 6 пунктлары 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 21 февраль
№ 12-ТРЗ